**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.04. 2022 № 127

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 06 августындагы 254 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законга, Әтнә районы прокурорының 06.04 № 2-08-02/Прдн161-22 протестына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 06 августындагы 254 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.5 пункытында «Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракта таләп ителми» дигән абзацына түбәндәге эчтәлектәге 1.1.) подпункт өстәргә:

«1.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү (өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, "Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән, реконструкцияләүдән тыш);

2.1. 2.5.1 пунктындагы 6 пунктчасына "блокланган төзелештәге барлык йортларның да хокук ияләренең бер рәттә төзекләндерелгән йортларның берсен реконструкцияләү очрагында ризалыгы" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә

район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов